ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 декабря 2022 г. № 7394

Башкарма комитетның 2022 елның 11 августындагы 4059 номерлы карары белән расланган, аукцион үткәрмичә, муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җир участокларында, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон формада, дәүләт йөкләмәсе (заказы) урнаштырыла, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр һәм социаль әһәмияткә ия дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә күчү буенча чаралар планын раслау турында» 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 11 августындагы 4059 номерлы карары белән расланган, аукцион үткәрмичә, муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3.1 пунктының өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2.6.1 пунктының 4 пунктчасында «ЭЭИ» сүзен «Россия Эчке Эшләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлектәге 2.6.1.2 пункты белән тулыландырырга:

«2.6.1.2 Гариза биргәндә гариза бирүче административ регламентның 2.6.1 пунктындагы 1 - 2 пунктчаларында күрсәтелгән документларны (мәгълүматларны) мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтләнгән затларның көчәйтелгән

квалификацияле имзасы белән расланган электрон документлар рәвешендә бирергә хокуклы.»;

4) 2.8.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктчасы белән тулыландырырга:

«4) шартнамә гамәлдә булган чорда аренда түләве (шул исәптән пеня) буенча бурычлар булу, шулай ук стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү турында гариза биргән вакытка стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен җир участогын арендалау шартнамәсе буенча җир участогыннан фактта файдалану өчен түләү буенча бурыч булу.»;

5) түбәндәге эчтәлектәге 2.13.3 пункты белән тулыландырырга:

«2.13.3 Органга шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза биргән көнне Органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гариза бирүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан, теркәү номеры, гариза бирү датасы һәм тапшырылган документлар исемлеге белән расписка бирелә.»;

6) 3.4.3 пунктының икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә башкарыла, әгәр ведомствоара запроска җавап әзерләүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.»;

7) 3.5.2 пунктындагы бишенче абзацта «кәгазь» сүзен «электрон» сүзенә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов